Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы
КАРАРЫ

2023 елның 25 декабре № 189

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Җир кодексына, Россия Федерациясенең 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Урман кодексына, Россия Федерациясенең 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Су кодексына, Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ ( 14.07.2022 ред.) Федераль Закон белән "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" РФ Хөкүмәтенең , "Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында" 2006 елның 9 июненләге 363 номерлы Карары, Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында" 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Законы нигезендә «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең 2023 елның 20 ноябрендәге "Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын тикшерү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләрен исәпкә алып, Кама Тамагы муниципаль район Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының 2023елның 17 апрелендәге 142 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә.https://cloud.mail.ru/public/hzBz/7pkhJAoKa

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында дәүләт теркәвенә алганнан соң (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе Н.А.Вазыйхов